КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 17 апрель г.Казань № 478

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төбәк оборона спорт-техника оешмасы – РОСТО (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт берләшмәсен «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасы (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсенә үзгәртү турында» 2008 ел, 4 июнь, 372 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасы (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсенең бердәм уставына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төбәк оборона спорт-техника оешмасы – РОСТО (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт берләшмәсен «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасы (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсенә үзгәртү турында» 2008 ел, 4 июнь, 372 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел 28 август, 617 нче, 2013 ел, 20 май, 328 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасы (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсенең бердәм уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктта «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Спорт министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

4.3.1 пунктчаның өченче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

4.3.2 пунктчада:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин